ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 1 30.10. 2020 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Иске Тимошкино авылында гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 22 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Иске Тимошкино авылы, Ленин урамы, 27 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 10 сәгать 00 минутта 2020 елның 09 ноябрендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Иске Тимошкино авылы, Ленин урамы, 27 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 14 сәгать 00 минутта 2020 елның 09 ноябрендә билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Иске Тимошкино авылында яшәүчеләрнең исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
   1) Первомай ур., Кызыл Армия ур., Болын ур., Яшел ур.;
   2) Гагарин ур., Елга аръягы ур., Ленин ур., Нагорный ур., Җиңү ур., Пушкин ур., Якты Юл ур., Целина ур., Мәктәп ур.;
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда үзара салым кертүгә Аксубай муниципаль районының Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш,

500 сум күләмендә бер тапкыр түләү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Тимошкино авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү, кардан чистарту);
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак ташны (ЩПС) сатып алу, грунтны һәм вак ташны күтәрү, җәю һәм тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2. Торак пунктлар чикләрендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- чапкыч сатып алу (триммер-2 данә),
- торак пункт эчендә чүп үләненнән территорияне чабу (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплану буенча) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә.

- насос станциясе белән идарә итү блогын алыштыру, (килешү буенча түләү)

5. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән халыкка хәбәр итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы

Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы: П. А. Мулеева